**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында**
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**10 декабрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Бакырчы авылы эчендәге Җәлил ур. буенча юлларны төзү һәм төзекләндерү;
- Бакырчы авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу;
- Бакырчы авылы зираты территориясендә инвентарь саклау өчен бина төзү.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Л.С. Семенова**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлеге башлыгы**
**урынбасары** **С.Г. Батталов**